СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 1А, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 1А йорты, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## "Җир салымы турында" 2022 елның 22 августындагы 58 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (29.12.2022 N 58, 29.11.2023 № 90 үзгәрешләр белән)

12.07.2024 N 176-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге уставына таянып, Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. "Җир салымы турында" 2022 елның 22 августындагы 58 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Әлеге абзацта күрсәтелгән шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш, торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Ф.И.Ахмадуллин